СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, hishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

**2015 елның 18 мартыннан** **№ 42-244**

**«Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 пунктның 1 пунктындагы «387 605,4» санын «388 131,9» санын белән алыштырырга;

1.1.1 пунктның 2 пунктындагы «387 605,4» санын « 388 471,9» саны белән алыштырырга;

1.1. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты дефициты «340,0 мең сум;

1.2 Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районының 2015 елга бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары» дигән 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Карарның «2015 елга Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» дигән 2 нче кушымтасын әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының 2015 елга чыгымнарының ведомство структурасы» дигән 7 нче кушымтасын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының 2015 елга бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнары төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү» дигән 9 нчы кушымтасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Карарның 12 пунктын түбәндәге эчтәлекле «12.4» пунктчасы белән тулыландырырга:

- ««12.4.» Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә авыл җирлеге бюджетына 2015 елда табигать саклау чаралары буенча чараларны тәэмин итүгә төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 2038,0 мең сум күләмендә исәпкә алырга».

6. Яңа Чишмә муниципаль районының ирекле калдыкларын әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә кредит бурычларын каплауга юнәлдерергә.

7. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль район Башлыгы В. М. Козлов